*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

# ТЫЛСЫМ+

Бишенче сан

Декабрь, 2015 нче ел

## Бу санда:




1 *Хуш киләсең, Яңа ел!*



2 *Могҗиза булуына ышанасызмы?*



3 *Юбиляр белән әңгәмә*



4 *Кыш бабайга хат*


## ХУШ КИЛӘСЕҢ, ЯҢА ЕЛ!

***Хөрмәтле коллегалар, укучылар, әти-әниләр!***

Яңа ел җитәргә санаулы көннәр генә калып бара. Сезнең барыгызны да Яңа 2016 нчы ел белән чын күңелдән тәбрик итәм. Сәламәтлек һәм бәхет-шатлык белән тулы көннәр, рухи байлык һәм күңел тынычлыгы телим. Хыялларыгызның һәр барчасы тормышка ашсын, бәхетләрегез ташып торсын. Эшләрегез уң булсын, чәчәк атсын, гаилә бәхетегез сүнмичә балкысын.

2016 нчы елда да гимназия укучыларына үзләренең талантлы, иҗади, аң-белемле булуларын, спортны яратуларын исбатларга язсын.

Укытучыларыбызның яңа идеяләре күп булып, аларны тормышка ашырырга мөмкинлекләр тусын. Укытучылар, әти-әниләр, укучыларның берләшеп, көйле эшләве гимназиянең район һәм республика күләмендә иң алдынгы мәктәпләр рәтендә булуына булышлык итәр дип ышанам. Көчләрне берләштереп, уңай нәтиҗәләргә ирешергә язсын.



Туасы яңа – 2016 нчы ел белән!

Бәйрәмегез мөбарәк, күңелле, куанычлы булсын.

***Хөрмәт белән,***
***А.Ф. Мирзаянов,***
***Мөслим гимназиясе директоры***

## Фән бәйгеләре көндәлеге



Барлык фәннәр буенча Бөтенроссия һәм республика олимпиадаларының муниципаль этабы тәгәлләнде. Уңышларыбызны барлар вакыт җитте. Гимназия укучылары 97 призлы урын яуладылар.

Үзләренең өстенлекләрен белемнәре белән исбат итә алган иң тырыш укучылар белән сез танышмы?

Барлык олимпиадаларда 8 нче а сыйныф укучысы Фәхертдинова Айгөл 10 призлы урын (3 җиңү, 7 призер) яулады, 10 нчы сыйныф укучысы Шәйгарданова Регина 9 призлы урын (6 җиңү, 3 призер) һәм 8 нче а сыйныфы укучысы Зиязова Миләүшә 8 призлы урын (1 җиңү, 7 призер) яуладылар.

Региональ һәм республика этабында зур җиңүләргә ирешүегезне телибез.

## Регионара семинарлар

Гимназия базасында башлангыч сыйныф һәм инглиз теле укытучыларының регионара семинарлары үтте. Семинарларда ФГОС буенча дәрес фрагментлары, мастер-класслар күрсәтелде.

Түгәрәк өстәл артында фәннәрне укыту буенча тәҗрибә уртаклаштылар.

Укытучыларыбызның эшчәнлеген яктырткан бай күргәзмә эшләде.





# МОГҖИЗА



Яңа ел ул – могҗиза!
Тылсым! Гаҗәп!
Әнә, кар ява әкрен генә
Яңа елны котлап.

Кемдер теләк тели
Нидер сорый, көтә.
Миңа бары тик
Якыннарым
Янымда булу җитә.

Кемгәдер телефон,
Коньки, компьютер кирәк.
Мин сезгә бәхет, саулык телим -
Менә шул минем теләк.

***Нуриева Ильвина***

**2015 ел нинди истәлекле вакыйгалар белән хәтерегездә кала?**

**Гөлназ Рәисовна:** 2015 нче елда минем күптәнге хыялым тормышка ашты - Кара дингез буена сәяхәткә бардым. Абхаз иленең табигате онытылмаслык хәтирәләр калдырды.

**Ләйсән Фәһәметдиновна:** “Ел укытучысы - 2015” конкурсы җинүчесе булдым. Египетта ял итеп кайттым. Укучыларым муниципаль олимпиадаларда 14 призлы урын алдылар.

**Римма Гайсовна:** 2015 нче елда мин ӘБИ статусына ия булдым: минем оныгым туды.

***P.S.***

Эльмира Василовна, Азилә Рамиловна, Алсу Расиховна - автоледи булдылар!

Дамир Гайнетдинович кабат эти булды - улы туды!

Азат Фаритович гаилә корды.

Гөлүсә Әсгатовна, Гөлнур Әзһәмовна “теща” булды.

Зөлфирә Мөһәровна, Рәмилә Сабирҗановна ӘБИ булдылар.



***Могҗиза булуына ышанасызмы? Үз тормышыгызда нинди үзгәреш булуын теләр идегез?***

***Ирина Тимерхановна:*** Ышанам. Кеше хыял белән яшәргә тиеш. Һава ничек кирәк булса, кешегә хыял да нәкъ шулай ук кирәк. Мине гомерем буе могҗизалар озатып бара. Ничек ышанмыйсың инде, после этого!?)) Үзгәрешләргә килгәндә... Киресенчә, шул килеш калсын дип телим. Мин тормышымнан канәгать.

***Ләйсән Габбасовна:*** Мин могҗизаларга ышанам. Бүген генә бер могҗиза булды: хат язмасам да, Кыш Бабай чыршы төбенә бик матур бүләк куеп киткән. Ул бүләккә кечкенә бала кебек сөендем. Кыш Бабай, чыннан да, бар икән, дип уйлап куйдым. Яңа 2016 елда, могҗиза булып, иң якын кешем - әтиемнең сихәтләнүен телим.

***Әгълиуллина Язилә:*** Могҗизага мин һәрчак ышанам. Ямьле иртәдә зәңгәр күктә сызылып аткан ал таңнар, кичке салкын һавада ялтырап коелган сыкы, җир астыннан бәреп чыгып челтерәп аккан чишмәләр күңелләргә моң сала. Киләсе елда шатлыклы вакыйгалар күбрәк булуын, дөньядагы сугышларның бетүен көтәм.

***Зиязова Миләүшә:*** Могҗиза! Нинди матур яңгырашлы сүз! Әлбәттә, мин могҗиза булуына ышанам. Могҗизага ышанудан туктаган кеше яшәүдән дә туктый, минемчә. Мин Яңа елда ни көтәм соң? Ышанмассыз, мин кышны көтәм. Ниндидер генә кыш түгел, ә ябалак-ябалак карлы, суык, чын матур кышны көтәм. Менә-менә килеп җитә язган иде бит инде кыш. Юк инде, җылытты да куйды... Чынлап әйтсәм, минем инде бөтен кирәк әйберләрем бар, Аллага шөкер, әти-әнием исән-сау. Минем бер зур хыялым бар: һава шарында очасым килә. Күктән безнең җиребезгә карыйсы, болытлар арасында йөзәсем килә. Менә Яңа елдан ни көтәм мин!

*******

Яңа елда һәркем хыялларының чынга ашуын тели. Беренчедән, Яңа елда минем мөгезле атны күрәсем, аңа утырып Мөслимне кошлар очкан биеклектән күзәтәсем килә. Икенчедән, Яңа елга Кыш бабай тылсымлы таяк бүләк итсә, мин аның белән үземә кирәкле әйберләрне алыр идем. Теләгемнең чынга ашуына ышанам.

***Ибраһимова Алия***

*******

Минем иң яраткан һәм көтеп алган бәйрәмнәремнең берсе - Яңа ел бәйрәме. Бар җирдә котлаулар яңгырый, иң изге теләкләр телиләр, күп бүләкләр бирелә, хыяллар чынга аша. Яңа елда һәр кеше үзенең хыялының тормышка ашуын тели. Кемнеңдер машина аласы, кемнеңдер самолётта очасы килә, ә минем хыялым - парашюттан сикерү. Парашюттан сикерү бик куркыныч булса да, бик тә сикерәсе килә. Хыялыма чын күңелемнән ышансам, ул берәр вакыт чынга ашар.

***Галимова Алсу***

******

Яңа ел - иң могҗизалы вакыт. Кешеләрнең барлык теләгән теләкләре шушы мизгелләрдә чынга аша. Яңа елда мин кешеләргә сәламәтлек теләр идем. Барлык чирләгән кешеләр терелсеннәр иде.

Мин дөньядагы иң матур илләр дип саналган Франция белән Бөекбританиягә сәяхәт кылыр идем. Теләк чынга ашсын өчен, аңа күңел белән ышанырга кирәк, ә мин беләм: минем теләкләр һичшиксез чынга ашачак.

***Фәхертдинова Айгөл***

## ЮБИЛЯР БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ



***Озак еллар директор урынбасары булган хөрмәтле хезмәттәшебез Мәрданшина Рушания Мөхтәр кызы 2016 нчы елга аяк басканда 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Сезнең игътибарыгызга аның белән әңгәмә тәкъдим итәбез.***

*Иң зур байлыгыгыз?*

*Гаиләм: Ирем – Таһирҗан, балалар, киявләр, биш оныгым, кода-кодагыйларым. Әнием һәм иремнең әти-әнисе.*

*Яшәү принцибыгыз?*

*Таш белән атканга, аш белән ат.*

*Көннең кайсы вакытында эшкә сәләтегез ныграк?*

*Сайларга туры килми, көн белән төннең тоташ эштә узган чаклары да күп. Иҗадилык, әлбәттә, төнге сәгатьләрдә көчлерәк.*

*Яраткан ризык?* Өчпочмак.

*Яраткан төс?* Ак.

*Кешеләрдәге иң яхшы сыйфат?*

Ышанычлы булу, сер саклау.

*Сез яратмаган иң начар нәрсә?*

*Гаделсезлек.*

*Иң курыккан нәрсә?*

*Билгесезлек.*

*Рушания Мөхтәровна, сез могҗиза булуына ышанасызмы?*

*Әлбәттә, ышанам. Шулай булса да, мин – "җир кешесе" – күктән төшкән могҗизаны көтеп утырмыйм, аны үзем тудырам. Максат куям, бурычлар билгелим, аннары шуңа таба акрынлап барам.*

*Хезмәтегез үзенчәлекле. Методик эшкә җитәкчелек итү белемле, эрудицияле булуны, һәрвакыт башкалардан бер адым алда баруны таләп итә. Бу осталыкка ирешүнең сере нәрсәдә?*

*Кеше күңеле һәрвакыт яктылык, матурлык, җылылык көтә. Үз күңелеңдә начарлык булмаса, синең тирә-ягыңа да гүзәллек тудыручы, якты күңелле, сөйкемле кешеләр җыела. Эшләү дәверендә минем янымда гел яхшы кешеләр булды. Коллегалар белән аңлашып эшләгәндә, теләсә нинди авырлыкларны җиңеп чыгарга була. Бу яктан мин үземне бик тә бәхетле дип саныйм.*

*Сүзебез бәхет темасына борылды. Кайсы өстенрәк: гаилә бәхетеме, әллә хезмәт китергән шатлык-куанычлармы?*

*Алар бер-берсен тулыландыралар, минемчә. Кечкенәдән укытучы булырга хыялландым, педагогия училищесы, институт тәмамладым. Мәктәп сукмаклары буйлап узган өч дистәдән артык гомер күз ачып йомган арада үткән бер мизгел кебек тоела. Бирелеп балалар белән эшләдем, методик эшне яратып башкардым – шуңадыр, үземне яшь итеп хис итәм. Беренче чиратта, гаиләдә якыннарың синең хезмәтеңне аңлавы әһәмиятле, әлбәттә.*

*Хәзерге яшьләр турында фикерегез нинди?*

*Заман үзгәргән саен, яшьләр дә үзгәрә. Яшьләр талантлы, кыю фикерле, максатка омтылучан. Миңа аларның креатив булулары ошый. Югалып калмыйлар, проблеманы чишүнең төрле юлларын күрә беләләр. Алар белән утка да, суга да керергә була.*

*Яңа елга нинди өметләр, теләкләр белән керәсез?*

*Яңа ел яңа бәхет китерсен, дип әйтергә яраталар. Яңа бәхет килү мәҗбүри түгел, булган бәхетемне Ходай күпсенмәсен. Ил-көннәргә иминлек телим, хәерле еллар килсен! Һәрберебезгә шатлык-бәхеткә тиенеп яшәргә язсын, сәламәт булыйк. Маймыл елы шәфкатьле, барчабызга мәрхәмәтле булсын!*



## ЯҢА 2016 ЕЛ

Яңа елны каршы алганда бәйрәм өстәленә нәрсәләр куярга, нинди ризыкларга өстенлек бирергә соң?

Маймыл барысын да ашарга мөмкин дигәннән чыгып, бәйрәм өстәлендә яшелчәләр, җиләк-җимеш, ит, балык, краб һ.б ризыклар булырга мөмкин. Маймыл балллы ризыклар да ярата. Шуңа бәйрәм өстәленә берничә төрле десерт әзерләргә дә мөмкин. Тик десерт составында банан, алма һәм башка җиләк-җимешләр дә булырга тиеш. Балыктан пешерелгән ризыкларга да өстенлек бирергә кирәк. Ә балык ул - тормыштагы бәхетле үзгәрешләр символы.

**2016 — Маймыл елын каршы алганда нинди кием кияргә, нинди аксессуарларга өстенлек бирергә? Һәр йолдызлыкка аерым киңәшләр тәкъдим итәбез.**

**Кучкар.** Чын ефәктән тегелгән кием киегез. Ә инде ул ачык төстә дә булса, Яңа ел мәҗлесендә иң зәвыклы булып күренерсез.

**Үгезбозау.** Игътибар үзәгендә булыр өчен, кызыл төстәге киемгә өстенлек бирегез. Зур түгәрәк алкалар да Маймылның күңеленә хуш киләчәк. Алкаларның алтын төсендә булуы да мөмкин.

**Игезәкләр**. Парлы аксессуарлар кулланырга киңәш ителә. Әйтик, бер кулыгызга беләзек кисәгез, икенчесенә дә шундый ук беләзек киеп куегыз.

**Кысла.** Яңа ел төнендә үтә дә серле булып күренегез. Мәсәлән, балмаскарадтагы битлекне киярге була. Маймыл өчен әлеге интрига бик тә кызык булачак.

**Арыслан.** Хайваннар патшасы буларак, чын мәгънәсендә падишаһ образында булырга кирәк. Маймыл 2016 елда баш булса да, арысланга баш иячәк. Шуңа күрә арысланга Яңа елда таҗ кисә дә килешле булыр.

**Кыз.** Маймылга якынрак булу өчен, романтик образ сайларга кирәк. Бу күлмәк озын һәм бизәкле булырга да мөмкин.

**Үлчәү.** Мехлы кием кисәгез, Яңа ел кичендә күз явын алырлык итеп күренерсез. Маймыл да бу образдан канәгать калыр.

**Чаян.** Сезгә ачык киемнәр килешә. Әйтик, кыска итәк кисәгез, теләсә кемне шаккатыра алачаксыз.

**Укчы.** Маймылга ярарга тырышып, артыгын кыланмагыз. Иң яхшысы — гади күлмәк сайлагыз.

**Кәҗәмөгез.** Яңа елга күлмәк түгел, ә зәвыклы чалбар алыгыз. Маймыл сезгә һичкшисез уңыш бүләк итәр.

**Сукояр.** Сезгә Маймылга ошар өчен тырышырга туры килер, шуңа күрә ялтыравыклы тукымаларга өстенлек бирегез.

**Балык.** Ни генә кисәгез дә, прическагызга аеруча игътибар бирегез. Яңа елда иң шәп прическа нәкъ менә сездә булырга тиеш.

Гомумән алганда, Маймыл — хәйләкәр һәм шаян хайван, шуңа күрә Маймыл елына кергәндә җитди, эшлекле киемнәр кимәгез. Сезнең образ матур, җиңел, төрле төсләргә бай булсын. Ә инде төсләргә килгәндә, Маймыл кызыл һәм сары төсләрне ярата.

# КЫШ БАБАЙГА ХАТ

***Исәнме, сөекле Кыш бабай!***

*Узган ел син җибәргән тимераяклар бик ошады, алар миңа бераз зуррак иде, быел инде тап-таман! Былтыр гаиләбез белән рәхәтләнеп Мөслимдә катокта шудык. Ишегалдыбызда да боз катырган идек, әтием һәм абыем белән туйганчы хоккей уйнадык.*

*Безнең Мөслим шундый матурланды, килгәч үзең дә шаккатырсың әле. Яңа парклар, балалар мәйданчыклары ясап бетерделәр. Казандагы кебек җәяү генә йөри торган урамнар да бар. Күп кеше хәзер велосипедта элдерә. Минем дә велосипедым бар! Экстрим-парк ясадылар. И-и, ниләр генә юк анда! Минем кебек малайлар-кызлар рәхәтләнә инде шунда уйнап! Роликлы тимераякларда йөрүчеләргә кызыгып карап торам: их, минеке дә булсын иде... Әтидән сорап караган идем дә, ул: "Аның иң шәпләре Кыш бабайда гына була. Әнә, узган елгы тимераякларың үзе шуа. Быел да соңга калмыйча хат язып сал," – диде.*

*Юмарт бабакаем! Миңа бер матур гына, уңайлы гына роликлы тимераяк җибәрә алмассың микән? Аз гына зуррак булса да, бик затлы булмаса да ярый. Әлегә йөри белмим, ләкин өйрәнәчәкмен, чын менә!*

*Кар-бураннарың, чеметкеч салкыннарың белән тизрәк килеп җитүеңне көтеп калам. Безгә дигән бүләкләреңне дә онытма, бабакай!*

***Булат Шәрипов, 2 нче а сыйныф укучысы***



*Исәнме Кыш бабай!*

*Сиңа сөенечле хәбәрем бар. Мин быел 1нче сыйныфка укырга кердем. Хәзер мин укый, яза беләм. Сиңа да бу хатны үзем язам.*

*Миңа быел бүләккә чаңгы алып кил әле, Кыш бабай. Бәлки син бүләк итсәң, карлар да күп итеп явар, көннәр дә суытыр иде.*

*Сине дә Яңа ел белән котлыйм һәм кунакка көтеп калам.*


***Фаррахов Ранис, 1 нче в сыйныфы укучысы***


*Исәнме, Кыш бабай! Минем иң-иң яраткан бәйрәмем - Яңа ел бәйрәме. Мин аны алдан ук көтә башлыйм.Теләкләремне язып,чыршы төбенә хат язып куям, ә син ел саен бүләк калдырып китәсең. Яңа елда миңа бик күп бүләкләр бирәләр, әмма синең бүләкне мин барысыннан да ныграк яратам! Чөнки ул - синеке, Кыш бабай!*

*Кыш бабай, дөньяда тормыш шартлары бик авыр балалар, хәтта тамагы ач балалар да бар. Син, зинһар өчен, эшең бик күп булып, аларны онытып җибәрә күрмә! Мин Җир йөзендәге барлык балаларның да Яңа елда бүләкле булуын телим!*

*Кыш бабай, без синең шома бозлавыкларыңны, ап-ак карларыңны, бураннарыңны бик яратабыз! Рәхмәт сиңа барысы өчен дә!*

*Сау бул, Кыш бабай! Чыршы бәйрәмендә очрашуны көтеп,* ***Сөмбел Галиева, 2 нче б сыйныфы укучысы.***





ТЫЛСЫМ+

Декабрь, 2015 нче ел

***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректорлар:** Муллагалиева Алсу, Солтанова Эльвина
**Корреспондентлар:** Сәфәргалина Инзилә, Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Нуретдинов Динар
**Компьютерда җыючылар:** Иванов Рафаэль, Хабибуллин Руслан
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym